РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОН

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район
4233308

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МЭЛБАГЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Нефтяниклар ур., 30 нче йорт, Мэлбагыш авылы, Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592)3-77-90,3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» сентябрь 2018 ел № 12

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына ярашлы 24.03.2004 № 23-ТРЗ "Җирле референдум турында", «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, карар бирәм:

1. Җирле референдум үткәрү инициативасы:

"Сез 2019 елда Мальбагуш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) ял оештыру һәм авыл халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;;

3) торак пункт территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру;

4) торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карар:
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында:
Мәлбагуш авылында Нефтьчеләр урамы, 30 йорт (Башкарма комитетның административ бинасы) ; Мәлбагуш авылында Җәлил урамы, 2 йорт ( авыл мәдәният йорты; Түбән Якеево авылында Кашапов урамы, 23 йорт (ФАП ); Каменка авылында Җәлил урамы, 1 йорт.

- түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы: http://pravo.tatarstan.ru,

-түбәндәге веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык И.А.Әхтәмова